Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы
карары

2025 елның 22 сентябре №1/6

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларны, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 24/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларны, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 24/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасының өченче абзацында «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3 пунктның тугызынчы абзацында «, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш.» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), авыл җирлегенең чикләнмәгән даирә затлары файдалана алырлык урыннарда урнашкан махсус мәгълүмат стендларына һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.В. Сашин